# Алмашлык

Татар теле 6 сыйныф Олы Кульга төп гомуми белем бирү мәктәбе.

Хуснутдинова Г.А.

# АЛМАШЛЫК

- Үзләрен атамыйча гына зат яки предметларга, аларның билгесе яки санына һәм хәлләренә күрсәтә (ишарә итә) торган сүз төркеме АЛМАШЛЫК дип атала.

# АЛМАШЛЫК ТӨРКЕМЧӘЛӘРЕ

Мәгънәләре буенча алмашлыкларның 7 төркемчәсе бар.

- 1. Зат алмашлыклары
- 2. Күрсәтү алмашлыклары
- 3. Билгеләү алмашлыклары
- 4. Сорау алмашлыклары
- 5. Юклык алмашлыклары
- 6. Билгесезлек алмашлыклары
- 7. Тартым алмашлыклары

# Зат алмашлыклары

- **Мин, без** – I зат – сөйләүчеләр.
- **Син, сез** – II  зат – тыңлаучылар.
- **Ул, алар** – III зат – сөйләмдә катнашмаган, әмма шулар турында сүз барган зат яки предметны белдерүчеләр.

# Күрсәтү алмашлыклары

- Күрсәтү алмашлыклары затка, предметка, аның билгеләренә күрсәтәләр.
- **Бу, ул, шул, шушы, әнә, менә, теге** – зат яки предметка күрсәтә.
- **Бу, шушы, менә** - иң якын аралыкны, **шул, ул** – уртача аралыкны, **әнә** - ерак аралыкны күрсәтә.
- **Андый, мондый, шундый** – предмет билгесенә ишарәли.
- **Алай, болай, шулай, шушылай** –эш-хәл билгесенә ишарәли.

# Билгәләү алмашлыклары

- Затларны, предметларны гомумиләштереп белдерәләр.
- **Бар, барлык, барысы, барча, барчасы, бөтен, бөтенесе, һәммә, һәммәсе** – зат, предметларга тулаем күрсәтәләр, күплек формасында булалар.
- **Һәр, һәрбер, һәрберсе, һәркем, һәрнәрсә, һәркайсы, һәртөрле, үз-үзе, үзләре** – аерым зат, предметларны белдерәләр.

# Сорау алмашлыклары

- Сорау формасында зат яки предметларга, аларның билгеләрнеә, саннарына һәм хәлләренә күрсәтәләр.
- **Кем, ни, нәрсә** - билгесез булган зат, предметка күрсәтү өчен кулланыла.
- **Нинди, кайсы** – зат, предмет билгесенә, **ничә, ничәнче, ничәшәр** – санына, ник, **ничек, нигә, ни өчен** – эш-хәлнең үтәлү сәбәбенә күрсәтәләр.

# Юклык алмашлыклары

- Предметны, билгене кире кагуны, аларның булмавын белдерә.
- Сорау алмашлыгы алдыннан *һич* яки *бер* сүзен ялгау белән ясала: һичкем, бернәрсә, һичнинди, беркайчан.
- Һич һәм бер сүзләре аерым булганда да юклык алмашлыгы булып киләләр.

# Билгесезлек алмашлыклары

- Билгесезлек алмашлыклары сорау алмашлыкларына әллә сүзе һәм –дыр, -дер; -тыр, - тер кисәкчәләре кушылып ясала: әллә кем, кемдер, ничектер.
- Алар билгесез зат, предметка (әллә кем, әллә нәрсә), аның билгесенә (ниндидер), санына (әллә ничә), эш-хәрәкәт билгесенә (әллә ничек) күрсәтәләр.

# Тартым алмашлыклары

- Предметның кайсы затка каравын белдерәләр.
- Кайбер алмашлыкларга –ныкы, -неке кушымчалары ялганып ясалалар: синеке, аныкы, тегенеке, моныкы.

# Алмашлыкларның җөмләдә кулланылышы

- Алмашлыклар җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре була алалар.
- Мин укыйм. ( ия)
- Бу ул! (хәбәр)
- Андый сүз әйтмә. (аергыч)
- Тегеләрдән зур сәлам. (тәмамлык)
- Менә шулай языгыз. (хәл)
- 7 яшендә Асияне – мине – чит шәһәргә алып китәләр. (аныклагыч)

# Алмашлыкларның җөмләдә кулланылышы

- Алмашлыклар җөмләләр арасында бәйләнеш чарасы хезмәтен дә үтиләр.
- Газинур яр кырыенда утыра, ул <u>шуннан</u> су өстен күзәтә.

# Алмашлыкларның ясалышы.

- Тамыр: мин, шул, әнә һ.б.
- Кушма: беркем, һичнинди һ.б.
- Парлы: андый-мондый, әнә-менә, алай-болай, аннан-моннан һ.б.
- Тезмә: әллә нинди, әллә кайчан һ.б.

# Алмашлыкларга морфологик анализ.

- Сүз төркеме.
- Төркемчәсе.
- Төрләнү-төрләнмәве.
- Нинди җөмлә кисәге.
- Ясалышы.